**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ШАШЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШАШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Новые Шаши. Тел. 3-23-23

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2024 г. № 10

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 28.02.2017 ел № 4 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибе”нә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2020 N 98-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 01.05.2019 № 71-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2024 елның 28 июнендәге «02-08-02-2024/Прдп272-24» протесты нигезендә, Әтнә муниципаль районының Яңа Шашы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Шашы авыл җирлеге җитәкчесенең 2017 елның 28 февралендәге 4 номерлы карары (21.07.2021, № 17, 03.04.2023 №6 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Яңа Шашы авыл җирлеге ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 10 пунктын төшереп калдырырга;

1.2. 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

“13. План-графикка түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә билгеләнгән сатып алуларның идентификация кодлары;

2) объектның исеме һәм (яисә) сатып алу объектларының атамалары;

3) сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс белән тәэмин итү күләме;

4) планлаштырыла торган сатып алуларны гамәлгә ашыруның сроклары (вакыты);

5) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы нигезендә

товарны, эшне яисә хезмәтләрне сатып алулар турында иҗтимагый фикер алышу турында мәгълүмат;

6) "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктында каралган тәртип белән билгеләнгән башка мәгълүмат."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы: М.С.Сабирҗанов